КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 апрель г.Казань № 378

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

«Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстан юл-транспорт комплексын (алга таба - Баштатюлтранс) тоту һәм үстерүнең төп идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең «Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын төзү максатларында Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге адресы буенча урнашкан сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенең 20 014 кв.метр мәйданлы 16:33:080514:363 кадастр номерлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 86 кв.метр мәйданлы, «ОТТО» транспорт-экспедиция компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте милкендәге (алга таба - алына торган җир кишәрлеге милекчесе) җир кишәрлеген (алга таба - алына торган җир

кишәрлеге) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны бастырып чыгарырга;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Баштатюлтранска Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге адресы буенча урнашкан сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенең 20 014 кв.метр мәйданлы 16:33:080514:363 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Вознесенский тракты. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районы территориясендә Җиңү проспектыннан «Волга» М-7 автомобиль юлына кадәр участок төзү» объектын урнаштыруны күздә тоткан территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында» 2021 ел, 06 сентябрь, 812 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты нигезендә тартып алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләре үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин